
ISSN 0868-4545



Салават күпере



Кызык-мызык яки гаҗәп хәлләр

Кадерле дускай!

Менә синең алда «Салават күпере» журналының әүвәлгеләренә хас китабы. Бу юлы без аны «Кызык-мызык яки гаҗәп хәлләр» дип атарга булдык.

Нәрсә ул — «кызык-мызык»? Кызык-мызык ул — мәзәкләр, көлкеле әсәрләр, шаян такмаклар дигән сүз. Ә нәрсә ул — «гаҗәп хәлләр»? Анысы инде — без укыган, ишеткән могҗизаи вакыйгалар, кеше ышанмастай хәбәрләр. Бу китаптан син аларның кечтеки генә өлешен үзең дә укырсың.

Хәзер синең игътибарга иң әүвәл мәзәкләр тәкъдим итәбез. Шуларны укыгач, бәлки син үзең дә энең-сеңелләрең, дус-ишләрең белән булган кызыклы хәлләрне исеңә төшерерсең һәм «Салават күпере» журналханәсенә җибәрерсең әле.

Мәзәк дигәннән, бик күп кешеләр мәзәкләрне җыялар, язып баралар. «Огонек» журналы байтак еллар «Юрий Никулин мәзәкләре»н биреп барды. Америкада бервакыт иң кызык мәзәк сөйләүчегә, иң күп мәзәк җыючыга конкурс үткәрелгән. Луизиана штатында яшәүче Джон Паркер исемле америкалы беркая карамыйча, яттан... 52 сәгать буена мәзәк сөйләгән һәм Гиннесс китабына кертелгән.

Ярый, дускай, ошбу китап-журналыбыз да синең һәм сыйныфташларыңның, дусларыңның юлдашы булсын дигән теләктә калыйк без.



Рәссам Диләрә НӘҮРУЗОВА

© "Салават күпере", 1998 ел

Ярый әле ат түгел

Вәсим:
— Ярый әле мин ат түгел: юкса йокларга ятар алдыннан дүрт аяк юасы булыр иде.



Сыерның да чәчен алалармы?

Әтисе улының чәчен ала икән. Үтмәс пәке башны шулкадәр авырттырган, малай чак кына кычкырмый калган. «Түзәргә кирәк, егетләр сер бирмәскә тиеш,» — дип юаткан ул үзен.


Менә берзаман сузып кына сыер мөгрәп җибәргән. Шунда малай, үзе дә сизмәстән:
— Әти, сыерның да чәчен алалармы әллә? — дип кычкырган.



Тәрбияле бала


Әнисе белән әбисе радиодан балаларга тәмтомны аз бирергә кирәклеге хакында тапшыру тыңлый. Моны ишетеп алган биш яшьлек Әнвәр сабыр гына әйтеп куя:
— Әйдәгез, тәрбияле кешеләр буларак, без бу киңәшне ишетмәдек дип уйлыйк.






Пеләш карандаш

Дүрт яшьлек Дамирдан әтисенең рәсемен ясавын сорыйлар.
— Булмый. Ясый алмыйм. Минем пеләш карандашым юк! — ди нәни малай.







Утлы йомырка

Безнең әбинең ак тавыгы бар. Ул көн дә кыткылдый-кыткылдый йомырка сала. Әби ак тавыгын бик ярата, аны төрле җимнәр белән сыйлый, ә йомыркаларын иләккә җыя бара. Ул иләктә ак тавыкның йомыркалары бик күп... Бер дә санап бетерерлек түгел. Ул йомыркаларның ничә икәнлеген әби үзе дә белми торгандыр әле...

Беркөнне әби, ах-вах итеп, ишектән килеп керде.

— Иләктә унбиш йомыркам бар иде. Ундүрткә калган. Унбишенчесе утлы йомырка иде. Мин аны күрше карчыктан алып, вакытлыча гына иләккә куеп торган идем. Их, харап булдык,— ди әби...

Мин бер сүз дә эндәшми торам. Ә әби минем күзләремә туп-туры карый. Алай текәлеп карагач, минем күзләрем оялалар.

— Башкасы булса бер хәл иде, утлы йомырка бит, утлы йомырка,— дип сөйләнә әби. — Болай бит пожар чыгачак. Ул авылыбыздагы өйләргә кабачак. Йомыркасы аның миңа берни түгел...

Колакларым ут кебек яна башлады. Үземә дә әллә ничек эссе булып китте... Әйтер идем — ул йомырканы мин сорамыйча алдым, әби орышыр. Әйтмәс идем — ул утлы йомырка белән кибет яначак...

Мин йодрыгым белән күзләремне уа башладым һәм:

— Әби, утлы йомырканы мин алган идем! — дип елап җибәрдем.

Әби әйтә:

— Харап булганбыз, әйт, кая куйдың? — ди.

Мин әйтәм:

— Җәмил белән кибеттән конфет алып ашадык.

Шунда ук әби каядыр чыгып йөгерде. Ахрысы, кибеткә киткәндер. Ә мин оялуымнан көн буе өйгә кайтмыйча йөрдем. Авыл өстендә бер нәни генә төтен күрсәм дә, куркып китәм. Ярый әле морҗадан чыккан төтен була.

Пожар чыкмады. Кич белән генә өйгә кайтсам, әле һаман йокламаганнар... Сеңелем Гөлчирә:

— Әнә, утлы йомырка кайтты! — дип көлә.

Ә башкалар көлмиләр. Мине чәй эчәргә чакыралар. Мин, песи кебек булып, бер кырыйга барып утырам.

Әби көлә-көлә чәй ясый:

— Йомырканың утлы булганын кайчан күргәнең бар?.. Тик зурлардан сорамыйча әйбергә тиярге ярамый,— ди.

Мин тагын кып-кызыл булам. Нигә сөйли торгандыр бу әби? Әйтерсең инде аны хәзер мин белмим.

(Абдулла Алиштан).



Рәссам Дамир ҖӘЛӘЛЕТДИНОВ

Яулыктан йомырка салдыру

Өстәл өстендә кара яулык белән капланган түбәтәй тора. Фокусчы, яулыкның ике ягын да күрсәтеп урталай бөкләгәннән соң, «кыт-кыт-кыт» дип такмаклап, яулыктан бер-бер артлы йомыркалар «салдыра» башлый.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Әзерлек сере һәм башкару. Кечкенә кара яулык (яисә каты кәгазь) алып, кырыеның нәкъ урта турысына кара җеп бәйлиләр дә эче суырып алынган йомырка (яки ак шар) тагып куялар (А).

Яулыкны беренче мәртәбә күрсәткәндә, йомырка түбәтәйдә була (А). Яулыкны җеп тагылган ягыннан тотып күтәргәндә, йомырка, җепкә ияреп менеп, яулык уртасында кала (Б) һәм, яулыктан «кыт-кыт-кыт» дип салдырганда, кире тәгәрәп түбәтәйгә төшә (В).



Әтәч менгән киртәгә

Такмак

Иртән торып тышка чыксам,
Әтәч менгән киртәгә.
Ундүрт бака җырлап йөри
Армиягә китәргә.

Әтәч менгән киртәгә,
Кикерикүк итәргә;
Әтәчкә дә хәбәр килгән
Армиягә китәргә.

Әтәч әйтә, бармыйм, ди,
Тавык әйтә, калмыйм, ди,
Син армиягә китсәң,
Бер күкәй дә салмыйм, ди.

Әтәч китте армиягә,
Чабатага утырып.
Тавык мескен карап калды,
Ике күзен тутырып.



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Төшеңә тавык керсә

Әгәр төшеңә тавык керсә — көтелмәгән кунак килер; күп тавык — кунаклар яки акча килүгә.



Һава торышы яки әтәч белән тавык

Йорт кошлары башларын канатлары астына яшерсә — көн салкынаер. Кыш көне әтәч үз вакытында кычкырмаса — көн җылыныр. Тавык койрыгын болгаса — җил чыгар.



Йомырка рекордлары

Бөекбританияле Дейл Лайоне 1990 елның 23 апрелендә кашыкка йомырка салып 48,1 км.ны 4 сәгать 14 минутта уза.



Әтәчләр, тавыклар

Авылдагы гади әтәчнең никадәр якын һәм ерак кардәшләре бар икәнен беләсезме сез? Алар бик күп. Салкын төньякта яшәүче ак кортлек тә, карасу-зәңгәр тестәге көртлек тә, караңгы тайгада яшәүче бик сак урман тавыгы да — аның туганы. Нәфис фазан да, гаҗәеп матур тавис та, кечкенә әтәч-бытбылдык та — аның туганы.

Австралиядә, Филлиппинда һәм Тын океандагы башка утрауларда чүп тавыклары яши. Алар чебиләрен чыгармый, ә чын инкубатор ясыйлар: төрле чүпләрне бер өемгә өеп, шунда йомырка салалар яки йомыркаларын җылы комга күмеп куялар. Шундый инкубатордан бик җитез чебиләр чыга. Алар беренче көннән үк оча башлыйлар.


Америкада агач тавыклары яши. Алар, үзләренең туганнарыннан аермалы буларак, ояларын агачка гына ясыйлар.

Йорт кошлары арасында да әтәчнең туганнары әллә никадәр! Күркәләр дә, мисыр тавыклары, төрле нәселдәге йорт тавыклары да — аның туганнары. Йорт тавыклары безгә тәмле һәм туклыклы продукт — ит һәм йомырка бирә. Алардан бик күп төрле ризыклар әзерләргә була. Тавыклар йон һәм мамык та бирә. Йомырка сала торган тавык бер ел эчендә 200-220 йомырка сала. Рекорд куючы тавыклар 365 йомыркага җиткерә.

Япониянең көньяк-көнбатышында һинд кызыл әтәчләрен үрчетәләр. Ул нәсел әтәчләренең койрыклары 10 метр 60 сантиметрга җитә.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ


Әкият
Бу рәсемдә кайсы халык
әкияте сурәтләнгән? Ул
әкиятнең исеме нинди?
Шуны исеңә төшер дә энеңә
яисә сеңлеңә сөйлә.




Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Мондый һинд әкияте бар: бөркетләр бер кызны урлап алып китәләр, үз ояларына алып кайталар да аңа Сүрә-бәй дигән исем-ат кушалар. Сүрә-бәй кояшханым дигән мәгънәне аңлата. Бервакыт Сүрә-бәйнең бармагына чәнечке кадала. Кыз шул чәнечке кадалудан үлә. Аны бер патша таба һәм гүзәл Сүрә-бәйнең бармагыннан чәнечкене тартып ала. Сүрә-бәй терелә һәм патшаның яшь хатыны була. Патшаның карт хатыны Сүрәбәйне буага төртеп төшерә. Гүзәл кыз шунда батып үлә. Ул батып үлгән менә шул урында алтын көнбагыш пәйда була...

Чынбарлыкта көнбагыш Төньяк Америкадан таралган диләр. Русиягә ул XVIII гасырда килеп эләгә. Голландиядә булган чакта Петр Беренче матур чәчәкле көнбагышны күреп ала һәм аның орлыкларын Петербургтагы даруханә бакчасына чәчәргә боера.

Баштарак көнбагыш декоратив үсемлек буларак кына үстерелә. Тора-бара аның орлыклары һәм мае халыкның иң яраткан ризыкларының берсенә әверелә.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ



Ләбиб Лерон

Сарыбаш белән Кояшбай

Әкият

Актаныш төбәгендә Олыймән дигән авыл бар. Менә шул авылда ишеттем мин Сарыбаш белән Кояшбай сөйләшүен...

— Беркөнне Кукмарага барып кайттым әле,— дип әңгәмәне башлап җибәрде Сарыбаш. — Ул таулары , ул таулары! Искитмәле инде менә!

— Арттырасыңдыр... Бер таудыр инде ул, — дип шиген белдерде Кояшбай.

— Әллә тагы. Ныклап карамадым да инде мин. Бәлки берәү генә булгандыр,— дип бик тиз килеште Сарыбаш. — Алай дисәң... Җырлаганда «таулары» дип җырлыйлар:

...Поездлар үтеп киткәндә
Тетрәп кала таулары...
Әй Кукмара, Кукмара...

— Тычкан шикелле чыелдама әле. Башны миңгерәүләтәсең бит,— диде Кояшбай.

— Ә син тыңлама! — диде Сарыбаш, үпкәчел тавыш белән.

— Тау дигәннән... Мин дә беркөнне Япониягә барып кайттым. Фудзияма тавына мендем. Ай-яй биек икән ул! Безнең авылдагы иң биек өйдән дә биек! Баскыч белән көчкә мендем Фудзиямага,— диде Кояшбай.

— Мин берәр көнне Керкәлегә барам әле,— диде Сарыбаш. Һәм җырлап җибәрде:

Керкәле таулары биек,
Биек булса да меник...

— Ә мин Азнакайга барам. Чатыр тауга! — диде Кояшбай. — Аннары Урал тауларына юл тотам...

— Ә мин Һималайга барам. Аннары Килимanджарога! — диде Сарыбаш.

Шулчак аларга Кояш эндәште:

— Әй, мактанчык хыялыйлар! Нинди тау ди ул! Сез бит басып торган җирегездән дә кузгала алмыйсыз. Моңарчы көнбагышларның илләр, таулар гизүен түгел, бер-ике адым атлаганнарын да күргәнем булмады...

— Мин... мин... төнлә бардым Кукмарага, — диде Сарыбаш.

— Хыялланырга да ярамый инде... — дип көрсенеп куйды Кояшбай.



Рәссам Сергей АНДРИАНОВ

Таптырый

Таптырый — шаян малай. Ул табышмаклар ярата. Бигрәк тә сорау-табышмакларны. Ул әйткән сорау-табышмакларга балалар җавап табалмыйча тинтерәп бетәләр. Таптырый аларның изалануларын күреп, рәхәтләнеп көлә генә. Табышмакның җавабын белгәч, балалар үзләре дә чыдый алмыйча көләргә тотыналар.

Таптырый үзе бик тә, бик тә яраткан сорау-табышмакларны журналыбыз битләрендә бирергә булдык әле. Йәгез, кем тизрәк аларның җавапларын таба?

Кунган кошны куркыт-мыйча гына ничек итеп агач ботагын кисеп ташларга?

Кош үзе очып китәч.

Кайсы ай календарьда юк?

Һавадагы ай.







Кем ике мәртәбә дөньяга туа?

Чебеш.

Сыер ни өчен ята?

Утыра алмаганга.



табышмаклары

Ач карынга ничә йомырка ашап була?

Берне.



Баш чаклы таш белән тәрәзә ватып буламы?

Юк. (Таш чебен башы кадәр генә булырга мөмкин.)





Рәссам Светлана ПРИВИНА

Нинди савыттан эчеп булмый?

Буш савыттан.







Башта, 4-5 яшьләрендә, Гөлназ әнисе ясап биргән рәсемнәрне буйый, шулай итеп төсләр дөньясында яшәргә өйрәнә. Аннары инде үзе дә ясый башлый. Ә хәзер, күрәсезме, сәнгать мәктәбендә укучы балаларныкыннан бер дә ким түгел аның эшләре.
Ә бит Гөлназ Хәйруллина авыл җирендә — Әтнә районында яши. Югары Сәрдә мәктәбендә укучы бу талантлы кызга хәзер 12яшь.




Рәсем ясыйм, хат язам.



Гөлназ мәктәпкә бара.







Әни һәм мин.



Көзге байлык.



Сабантуй батырына
мин чиккән сөлге.



Безнең эрага кадәр IV гасырда Александр Македонский сугышчылары Һиндстанга киләләр. Биредә алар үзләре моңарчы күрмәгән бик күп гаҗәеп әйберләргә тап булалар. Шундый әйберләрнең берсе — татлы могҗиза шикәр була. Шикәр сүзе бик күп илләрдә әз генә үзгәртелеп хәзер дә шулай саклана. Һиндстанда шикәрне шикәр камышыннан әзерлиләр һәм Африкага, Ауропага, Америкага озаталар.

Русиядә беренче шикәр заводы XVIII гасыр башында Петр Беренче фәрманы белән Петербургта төзелә. Шикәрне чит илләрдән кертелгән чималдан хәстәрлиләр.

XVIII гасыр ахырында Русиядә шикәр камышын шикәр чөгендере алыштыра.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ





Ак Ша

тә сөт э

Барып к

— Исә

Сатуч

— Сау

— Ми

— Акч

сатучы.

— Юк

нәүмиз



«Минем үземн...

алганнар иде, димәк, сөтне дә бушка бирмиләр. Ә бит уйлап карасаң, сыер сөтне бушлай бирә бит. Туктале, барыйм әле мин сыер янына...»

Килгән ул сыер янына. Дәшкән:


— Сыер ханым-туташ-иптәш-әфәнде, — дигән Ак Шакмак, үзеннән өлкәннәргә шулай мөрәҗәгать итәргә кирәк дип уйлап, — миңа сөт бирмәссең микән?

— Энем-сеңелем, мистер-твистер, сэр-мэр, господа, чынаягың бармы соң? — дигән сыер.

— Чын аякларым икәү. Ләкин мин чын кулларымның учына салып эчәр идем сөтне, — дигән Ак Шакмак.

Сыер биргән сөтне шикәр шундук эчеп бетергән һәм шул ук мизгелдә Сөтле Шакмакка әверелгән.

Сөтле Шакмак турында минем үземнең ишеткәнем бар иде моңарчы. Ләкин күргәнем юк.



Рәссам Светлана ИБРАҺИМОВА



Мырау быргы кычкырта, Чуарбай җырлый-җырлый гармун уйный... Әлеге шаян рәсемнәргә карап, тугыз аерманы табып кара әле.



Рәссам Максим ПОКАЛЕВ



Гаҗәпме? Гаҗәп!

Озак яшәүче мәче

Гадәттә, мәчеләр этләргә караганда озаграк яшиләр. Девонда яшәгән Пуси атлы мәче — чыннан да, озак яшәүче. 1839 елның 28 ноябрендә ул 36 яшен бәйрәм итә... һәм икенче көнне үк үлә.

Иң авыр мәче

330 мәче нәселе арасында иң зурысы — регдолл. Бу нәселле мәчеләр, гадәттә, 6-9 кг авырлыкта булалар. Чемпион исемен Австралиядә яшәүче Хилеми исемле мәче яулый. 10 яшендә ул 21 кг авырлыкта була.

Яңгыр явасын эт әйтә...

Эт кышын карда казынса — иртән буран, җәен җирдә казынса — яңгыр көт. Көннәр җылынасы булса, эт җиргә сузылып ята.

***

Песи идәндә озак йокласа, көн җылыныр. Буранга булса, аягы белән стенаны тырнар, койрыгын яласа — көн бозылыр, аякларын яласа — яңгыр явар.

Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Бу журналдагы язмаларны Ләбиб Лерон әзерләде.

Сәләвәт күпере

10(103) - 1998

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМАТ ҺӘМ МАТБУГАТ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ 1990 елның март аеннан бирле чыга

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства информации и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке.
Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары - җаваплы сәркатип
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Светлана ЯРКОВА рәсемнәре

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 8.10.98 ел.
Басарга кул куелды 8.10.98 ел.
Кәгазь форматы 84x108 1/16.
Басма табак 1,5 (2,1).
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 17200 данә. Заказ Я-473.
Бәясе килешү буенча.

POINT

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

